# САРА САДЫЙКОВА

# АК КАЛФАК

ҖЫРЛАР

КАЗАН   ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ   2006

УДК 784
ББК 85.319я 438
С15

Төзүчесе

*ЛЮБОВСКИЙ ЛЕОНИД ЗИНОВЬЕВИЧ*

**Садыйкова С.Г.**

Ак калфак: Җырлар / Сара Садыйкова; Төз. һәм кереш сүз авт. Л.З.Любовский.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 152 б.

ISBN 5-298-01459-3

Әлеге китапка татар халкының күренекле композиторы Сара Садыйкованың популяр әсәрләре белән беррәттән аз билгеле булган җырлары тупланды.

Нотное издание

*Садыкова Сара Гарифовна*

БЕЛЫЙ КАЛФАК

*Песни*

Составитель, автор вступительной статьи **Любовский** Леонид Зиновьевич

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Ноталы басма

*Садыйкова Сара Гариф кызы*

АК КАЛФАК

*Җырлар*

Төзүчесе һәм кереш сүз авторы **Любовский** Леонид Зиновьевич

Музыкаль мөхәррире *И.И.Байтирәк*. Мөхәррире *И.Г.Ногманов*. Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*. Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*. Компьютерда ноталарны җыючысы *Р.Ә.Моратов.* Корректоры *Л.З.Шиһапова*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.12.2006. Форматы 60□90 1/8. Офсет кәгазе. «Baltica» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 19,0. Шартлы буяу-оттиск 20,0. Нәшер-хисап табагы 17,49. Тиражы 1000 экз. Заказ З-1093. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru** **e-mail: tki@tatkniga.ru.** Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066.

Казан, Декабристлар урамы, 2.

ISBN 5-298-01459-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Любовский Л.З., төзү, 2006

# ТӨЗҮЧЕДӘН

*Сара Садыйкова сирәк очрый торган музыкаль сәләткә, тумыштан килгән талантка ия шәхес иде.*

*Профессиональ җырчы буларак, татар авторларының әсәрләре белән беррәттән ул халык җырларын да яратып башкара. Ләкин болар гына аны канәгатьләндерми, ул*

*үзе дә, татар музыкасына моңа кадәр ят булган яңа интонацияләр һәм жанрлар кулланып, көйләр иҗат итә башлый.*

*С.Садыйкованың йөз еллыгы уңаеннан чыгарыла торган әлеге җыентыкка композиторның клавир формасында тавыш һәм фортепиано өчен язылган җырлары тупланды.*

*Татарстан Республикасының Дәүләт архивына, радиокомитетның музыкаль тапшырулар редакциясенә, барлык танылган башкаручыларга һәм исемнәре аз билгеле булган җырчыларга, бигрәк тә бу эштә минем зур ярдәмчем, әнисенең иҗатын тирәнтен белүче Сара Садыйкованың кызы Әлфия Газиз кызы Айдарскаяга чиксез рәхмәтемне белдерәм.*

*Л.Любовский*

### Ак калфак көе

*Мирхәйдәр Фәйзи* сүзләре
Ак калфагымның чуклары
Кара чәчкәйләремә төште.
Синең лә миңа буласың юк,
Мәхәббәтем сиңа ник төште?

Ак калфагымның чуклары
Төшеп тора, бәгърем, күземә.
Минем дә сиңа күңелем төште,
Тиң булмыйсың, бәгърем, үземә.

## Җил икән...

*(Тын сукмакта тал тирбәлә)*

*Хәсән Туфан* сүзләре
Тын сукмакта тал тирбәлә,
Кулың талга тиядер,
Йөрәк әйтә, сагынгандыр,
Су буена киләдер.

Таллар тагын тирбәлделәр,
Иеләләр, күрәмсең,
Чәчләреңнән сыйпап синең
Сөенәләр, күрәмсең.

Таллар шулай тирбәлүне
Киләсеңдер син дисәм,
Син түгел лә, син түгел шул,
Син түгел ул, җил икән.

Җил икән, җил икән...

### Ник соңладың?

*(Романс)*

*Илсөяр Ганиева* сүзләре
Таң атканда, бер сандугач сайрый,
Дуска тиңләп ялгыз тирәкне.

Нигә соңлап килдең, асыл кошым минем,
Дулкынлатып моңсу йөрәкне?

Аерылган аккошлар шикелле,
Мин дә синең кебек моңаям.
Гомерем буйларына яндырырга мине
Соңлап кына килдең син каян?

Яшьлегемнең алсу таңнарында
Юк идең бит, нигә килмәдең?
Аерылсак та, җуймас йөрәккәем сине,
Зарыгып кына көткән тиңнәрен.

### КИЧКЕ НУРЛАР

*Мостафа Ногман* сүзләре
Алтын нурларга уралып,
Камада шәфәкъ бата.
Кама буйларында үскән
Яшьләр җырлашып кайта.

Күк читендә балкый тулган ай.
Кичке нурларда тирбәлә
Ямьле Исәнбай.

Шул җирләрдә үтә безнең
Җәйләребез, кышыбыз.
Канатлы яшьләр үстерә
Бәхетле тормышыбыз.

Күк читендә балкый тулган ай.
Кичке нурларда тирбәлә
Ямьле Исәнбай.

Кичке моңнар күңелләргә
Сүрелмәс дәртләр бирә.
Киләчәк матур көннәргә
Йөрәкне җилкендерә.

Күк читендә балкый тулган ай.
Кичке нурларда тирбәлә
Ямьле Исәнбай.

### ГОРУРЛЫГЫМ

*Нурмөхәммәт Хисамов* сүзләре
Кеше җирдә йорт-җир, нигез кора,
Тимәсен дип җилләр, салкыннар.
Зур илемдә минем шундый йортым —
Республикам, туган халкым бар.

Бу дөньяда мин бер ятим түгел,
Горурлыкка тулы хакым бар;
Тигезләргә мине тигез иткән
Республикам, туган халкым бар.

Ямансулап калсам мин еракта,
Үзәгемә үтсә салкыннар,
Җылысына кайтып сыенырга
Республикам, туган халкым бар.

### Серле кара күзләр

*Мәрфуга Шәехова* сүзләре
Серле кара күзләр, матур итеп
Карадыгыз минем күземә.
Нигә карап, нигә ут салдыгыз,
Кызганмыйча, минем күңлемә?

Серле кара күзләр, йолдыз булып
Сез янарсыз минем күңелемдә,
Кайгым-шатлыгым да сезнең белән,
Тик сез генә яшисез күңлемдә.

Кара күзләр, сезне беркайчан да
Оныта алмас янган йөрәгем.
Сезне генә сөю, сезне күрү
Булыр минем соңгы теләгем.

### КАЙЛАРДА СЕЗ?

*Нурислам Хәсәнов* сүзләре
Исәннәрдер әле, дия күңел,
Сагынулардан йөрәк уела.
Кайчан да бер миңа, кайчан да бер
Кайтып килерсез күк тоела.

Кушымта:
Күңел көтә газиз балаларын,
Кайтырсыз дип, бәлкем, берегез;
Күңел көтә һаман, зарыгып көтә.
Кайларда сез? Хәбәр бирегез.

Хәбәрсезләр дигән сүзгә никтер
Ышанасы килми һаман да.
Чит җирләрдә миңа тик адашып
Йөрисездер кебек яланда.

Кушымта.

Мәйданнарга чыгып басып торам,
Карашымны төбәп һәйкәлгә...
Бер килмәсә, әле килер кебек
Сәлам хатларыгыз әнкәйгә.

Кушымта.

### АВЫЛЫМ — АЛТЫН БИШЕГЕМ

*Хәмзә Бәдретдинов* сүзләре
Таң белән эшкә озата

Йөгерек чишмә суларың —
Уң булсын дип, нур булсын дип
Җир өстендә юлларың.

Кушымта:
Җырлар җырлап синдә үстем,
Синдә яшим, Сатмышым,
Син минем алтын бишегем,
Минем якты язмышым.

Җанымның балкышы булып
Туа алсу таңнарың,
Сәламләп иген кырында
Хезмәт алдынгыларын.

Кушымта.

Синдә генә бәхетебез,
Кояшыбыз, нурыбыз.
Җирдә иген шаулаганда,
Күктә тургай булырбыз.

Кушымта.

## ГОМЕР

*(Танго)*

*Гәрәй Рәхим* сүзләре
Вакыт җиле җәүһәр ташларның да
Җуя бара асыл төсләрен.
Яши-яши инде сүнә бара
Яшьлектәге кайнар хисләрең.
Яшьлектәге кайнар хисләрең.

Кушымта:
Ә ай шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!

Вакыт җиле горур кыяларның
Кыяфәтен тәмам үзгәртә.
Онытыла җанда олы кайгы,
Зур яралар бетә йөрәктә.
Зур яралар бетә йөрәктә.

Кушымта:
Ә ай шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!

Вакыт җиле кисә гомерләрне.
Бәлки, яшәү кирәк тә түгел?
Юк, ашыкма, җирдә яшәү өчен
Зур сәбәп бар әле, әй, күңел.
Зур сәбәп бар әле, әй, күңел.

Кушымта:
Ай бит шул ук кала,
Кояш шул ук кала,
Йолдызлар да кала —
Димәк, сөю кала!

## Картаймагыз әле, ветераннар!

*Гәрәй Рәхим* сүзләре
Картаймагыз әле, ветераннар,
Европаны саклап калган ирләр!
Җиңү бәйрәмнәрен якынайтып
Үттегез сез күпме илләр,
Үттегез сез күпме җирләр,
Үттегез сез, батыр ирләр!
Җиңү бәйрәмнәрен якынайтып
Үттегез сез күпме илләр,
Үттегез сез күпме җирләр.

## Чирмешән

*Мостафа Ногман* сүзләре
Чирмешән буйлары — яшел тугай,
Кырларында алтын бодайлар,
Шул җирләрдә бергә уйнап үскән
Яшьлегемнең дусты берәү бар.

Кушымта:
Чирмешән...
Бормаланып аккан Чирмешән.
Аның белән бергә
Булсам мин гомергә,
Бәхет йолдызыма ирешәм.

Чирмешән буйлары — бөдрә таллар,
Сабаклары суга иелгән,
Талчыбыктай зифа буе белән
Һич кенә ул китми күңелдән.

Кушымта.

Чирмешән буйларына кайтмый калсам,
Бик күрәсем килеп юксынам.
Җилфердәтеп зәңгәр яулыкларын,
Иркәм каршы чыгадыр сыман.

Кушымта.

СИНЕ ОЗАТКАНДА

*(Ак пароход китеп бара)*

*Нәби Дәүли* сүзләре
Ак пароход китеп бара,
Китеп бара еракка.
Әллә билгесез тарафка,
Әллә син торган якка.

Кушымта:
Акчарлаклар канат болгый,
«Хуш» диләр микән алар,
Минем генә сагышымны
Белмиләр икән алар.

Син дә шулай киткән идең,
Озатып калган идем.
Сине сагынып үтә еллар,
Тын гына ага Идел.

Кушымта.

Офыкларда зәңгәр томан:
Шатлыгыммы, кайгыммы?
Ак пароход китеп бара,
Сине алып кайтырмы?..
Кушымта.

Беренче тапкыр күрүем

*Хәсән Туфан* сүзләре
Беренче тапкыр күрүем,
Шулай да таныйм кебек...
Күзләрең аша йөземә
Язмышым карый кебек...

Сурәтең хыял күгендә
Ай булып туган иде;
Тик минем ялгыз йөрәктән
Еракта сыман иде...

Беренче күрү таңының
Аягы җиңел микән?..
Үкенечкә булыр микән ул,
Бәхетләр китерер микән?..

Ешрак яз, Әнием, хатларыңны

*Рәшит Фазлыев* сүзләре
Еракларда минем туган ягым,
Еракларда сөйгән авылым.
Ешрак яз, әнием, хатларыңны,
Бигрәкләр дә сине сагындым.

Кошлар очса әгәр сезнең якка,
Сәлам әйтеп калам артыннан.
Мин үзем дә очар кошлар кебек,
Күңлем белән сиңа ашкынам.

Сагынадыр диеп мине уйлап,
Көтәсеңдер, әнкәй, моңаеп.
Сезнең якта көн дә кояш чыга,
Алсу йөзең кебек елмаеп.

Яшь күңел

*(Син яшь, диләр)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Син яшь, диләр, һәрвакыт яшь күңелле, диләр,
Көннән-көн яшәрәсең, дип, миннән көнлиләр.
Яшәрәм, дусларым, чөнки мәңге яшьлеккә гашыйк мин,
Шуңа күрә картаерга бер дә ашыкмыйм.

Син шат, диләр, һәрвакыт шат күңелле, диләр,
Шат күңелле булуыңның серен әйт, диләр.
Шатланам, дусларым, чөнки мин яшим бәхет илендә,
Чәчәк аткан гөлбакчадай туган илемдә.

Син бик уңган, карлыгачтай бик җитез, диләр,
Колхоз кырларында эшләп үстеңме, диләр.
Эшләп үстем, дусларым, сандугачлар җырларын тыңлап,
Шуңа күрә сандугачтай яшим мин җырлап.

КАЗАН УТЛАРЫ

*Әхмәт Ерикәй* сүзләре
Кичке Иделдә
Йолдыз салютлары,
Балкып тора ераклардан
Казан утлары.
Балкып тора ераклардан
Казан утлары.
Казан утларына карап
Җырла син җырыңда
Тормыш язына ямь биргән
Илең турында.

Кичке Иделдә
Тирбәлә дулкыннар,
Күңелләрне иркәлиләр
Ягымлы моңнар.
Күңелләрне иркәлиләр
Ягымлы моңнар.
Беләсең, сине Казанда
Көндез дә, кич тә
Кара күзләр — нурлы йөзләр

Зарыгып көтә.

Туган Иделдә —
Диңгездәй киң җирдә —
Матур хисләр чәчәк ата
Йөрәк түрендә.
Матур хисләр чәчәк ата
Йөрәк түрендә.
Кайда гына йөрсәң дә син
Айкап Җирнең шарын,
Беркайчан да онытталмассың
Казан утларын.

## Әйт, дускаем, Әйт

*Рәгидә Янбулатова* сүзләре
Дим өстендә ай нурлары
Йөзә моңлы җыр булып.
Төнбоеклар тирбәләләр
Ак чәчәкләрен йомып.

Кушымта:
Йөрәгем яна,
Ашкына күңел,
Бу бер дә юкка, тикмәгә түгел.
Бу — тәүге сөю, тәүге мәхәббәт.
Миңа нишләргә? Әйт, дускаем, әйт!

Тынык Димдә толымнарын
Юа тал иркәләнеп.
Төнбоеклар уянырга
Көтә таң иртәләрен.

Кушымта:
Йөрәгем яна,
Ашкына күңел,
Бу бер дә юкка, тикмәгә түгел.
Бу — тәүге сөю, тәүге мәхәббәт.
Миңа нишләргә? Әйт, дускаем, әйт!

## Соңгы минутлар

*Мәрфуга Шәехова* сүзләре
Соңгы тапкыр, бәлки, алсуланып
Таң аткандыр минем күңелемдә.
Бәлки, соңгы тапкыр күргәнмендер
Моңсу шәүләм синең күзеңдә...

Минем өчен, бәлки, соңгы тапкыр
Ай чыккандыр күкнең йөзендә.
Бәлки, соңгы тапкыр соңгы яшем
Ялтырыйдыр моңсу күземдә.

Үтәр төннәр, тагын таңнар атар,
Йолдыз сүнәр күкнең йөзендә.
Сагынырсың мине, сагынырсың...
Яшьләр тамар синең күзеңнән.

Илебез яшәр, яшьлек чәчәк атар,
Син сыкранып мине эзләрсең...
Сине сөйгән дустыңны табалмый
Озак еллар, янып көярсең.

## ӘнисӘм

*Гариф Палютин* сүзләре
Йөргән юлларыңда күреп,
Әнисәм, сиңа килсәм,
Син дә миңа гына карап
Иркәләнеп бер көлсәң...

Кушымта:
Җилдә тибрәнгән таллар күк
Тибрәнер иде йөрәк.
Язның ягымлы һавасын
Киң сулар иде күкрәк.

Ай нуры яктырта җирне,
Ә син кемне, Әнисәм?
Яшьлегемнең таң йолдызын
Синең күзеңдә күрсәм...

Кушымта.

Елмаерсыңмы, Әнисәм,
Яныңа якын килсәм?
Ачуланмассыңмы, әгәр,
Мин сине сөям, дисәм?

Кушымта.

## кҮзлӘреҢ, кҮзлӘреҢ...

*Касыйм Тәхау* сүзләре
Күзләрең, күзләрең, күзләрең, иркәм,
Күзләдем, күзләдем күзләрең иртән.
Уйчан зәңгәр күзләрең лә
Нинди матур, нинди күркәм!
Карап туймыйм,
Карап туймыйм
Сиңа, иркәм!

Күзләрең, күзләрең, күзләрең, иркәм,
Түзмәдем, түзмәдем, күзләдем иртән.
Сирпеп торган керфекләрең
Йөрәгемә бирде ялкын!

Юктыр миңа,
Булмас миңа
Синнән якын!

Күзләрең, күзләрең, күзләрең, иркәм,
Түзмәдем, күзләдем үзләрен иртән.
Әйтерсең лә каш астыңа
Ике йолдыз төшкән күктән.
Кирәк түгел,
Кирәк түгел
Миңа бүтән.

### БЕЛЕГЕЗ ШУНЫ

*Илгизәр Фазлуллин* сүзләре
Иртә таңнарда карыйм талларга,
Өзә үзәкне кошларның моңы.
Аерылсам сездән, якын дусларым,
Саргаер идем, белегез шуны.

Көзләр җитүен, кошлар китүен
Азмы кичерде гомерләр юлы?!
Кояшлы җәем, чәчәкле язым
Сез ул, дусларым, белегез шуны.

Нурлана күзләр, тәмләнә сүзләр,
Бетә таралып күңелнең шомы.
Күрсәм яңадан сезне, дусларым,
Бәхетем арта, белегез шуны.

### Без яшӘгӘн ӨйнеҢ бусагасы...

*(Романс)*

*Роберт Әхмәтҗан* сүзләре
Без яшәгән өйнең бусагасы
Саклый сыман синең адымың...
Тоткаларда синең кул җылысы,
Шәүләң йөри сыман, акыллым!..

Бөтен нәрсә сине көтә анда,
Сине сагына, килче, тарсынма.
Сине көткән гөлләр моңсу анда,
Хәтерләтә сине барсы да.

Без яшәгән өйнең бусагасы
Саклый сыман синең эзләрең.
Тәрәзәмдә ике йолдыз яна,
Тәрәзәмдә — синең күзләрең!

Еллар аша балкый күзләрең.

### КашларыҢ карасына ла...

*Равил Фәйзуллин* сүзләре

Карасалар карасыннар
Кашыңның карасына.
Чит карашларны үткәрмә
Керфекләр арасына. 2 тапкыр

Кашларың карасына ла,
Гөл куйдым арасына.
Тик синең карашың дәва
Йөрәгем ярасына. 2 тапкыр

## КОЯШ ЧЫККАН, БАТКАН ЯКТА

*Рамазан Байтимеров* сүзләре
Сугыш уты кинәт каплап алды
Тыныч иртә, аяз ал таңны.
Ил уллары бердәм яуга китә,
Саклар өчен газиз Ватанны. 2тапкыр

Күп батырлар илгә җиңеп кайтты,
Ә берәүләр ятып калдылар.
Кояш чыккан, баткан якка карап
Көтә-көтә күзләр талдылар. 2 тапкыр

Җан кыелды азмы, кан коелды
Авыр көрәш барган якларда.
Бәлки, шуңа кояш кызарадыр
Чыккан чакта, баткан чакларда. 2 тапкыр

Бәлки, шуңа кояш кызарадыр
Чыккан чакта, баткан чакларда.

## Якты Өмет

*(Төнге җыр)*

*Рәфикъ Юныс* сүзләре
Тамчы-тамчы ак йолдызлар
Күңелемә тамалар.
Ак уйларым ераклардан
Сине эзләп табарлар.
Якты-якты өмет күрәм
Айның уйчан йөзендә.
Син дә хәзер ай-йолдызлы
Төн чатыры эчендә.

Татлы-татлы хыяллардан
Мөмкин түгел арыну.
Сагынасым килеп тора,
Арткан саен сагыну.
Якты-якты өмет күрәм
Айның уйчан йөзендә.
Син дә хәзер ай-йолдызлы
Төн чатыры эчендә.

## СӨмбел

*Әхмәт Ерикәй* сүзләре
Ак калфагың чиккән, бөккән,
Ука белән чукланган.
Ай Сөмбел, вай Сөмбел (лә),
Сөйгәнемне үзең бел!

Илнең матур егетләре
Ай йөзенә сокланган.
Ай Дилбәр, вай Дилбәр,
Күңлең күктәй киң, диләр.

Кәмәр буган, матур булган
Кайсы илнең баласы?
Ай иркәм, вай иркәм,
Сөйгән егетең кем икән?

Ак калфагын кыңгыр салган
Кайсы егет җанашы.
Ай чәчәк, вай чәчәк,
Матур исемең чәчеләчәк.

Синнән матур кызлар юк, дип,
Исемең илгә чәчеләчәк.

## Якты елга моҢнары

*Риза Ишморат* сүзләре
Якты елга буе — яшел алан,
Як-ягында назлы бөдрә тал.
Яшәвеңнән мәгънә табалмасаң,
Бөдрә талга карап гыйбрәт ал.

Якты елга, бөдрә таллар
Иркәлиләр күңелне,
Бу дөньяның гүзәллеге
Менә шулар түгелме?..

## БезнеҢ Җыр

*Рәдиф Гаташ* сүзләре
Ул аклык, ул сафлык турындадыр,
Гаҗәпмени, өзми кабатласак?
Бәлки, ул тик безнең, безнең җырдыр!
Ул — безнең якты моңдыр!
Кушымта:
Ничә мыскал энҗең,
Әй, ак калфак?
Их, мәңге ак калсак!

Ул вәгъдә, ул сөю турындадыр,
Ул яшьлектер безнең, гел җырласак?

Бездән соң да кемдер аны җырлар,
Без янган кебек янар!
Кушымта:
Ничә мыскал энҗең,
Әй, ак калфак?
Их, җырдай яшь калсак!

Ул тормышның үзе турындадыр,
Мәңгелек моң, җирдә ул калачак.
Бәлки, безне кемдер искә алыр,
Бәлки, онытылмас бу җыр!
Кушымта:
Ничә мыскал энҗең,
Әй, ак калфак?
Их, мәңге пакь калсак!

## шӘһӘр тӨшлӘре

*Илдар Юзеев* сүзләре
Яратсам да мин шәһәр кичләрен,
Авылга тарта матур хисләрем.
Туган ягыма, бала чагыма
Кайтара мине шәһәр төшләре.

Авылым таңнары, тыныч кичләре,
Яшел келәмдәй чирәм өсләре.
Туган ягыма, иң яшь чагыма
Кайтара мине шәһәр төшләре.

Зәңгәр елгалар, чәчәк исләре,
Яшел болыннар, печән исләре.
Туган ягыма, иң саф чагыма
Кайтара мине шәһәр төшләре.

## кҮҢеллӘрдӘ урын тармыни?

*Заһид Фәйзи* сүзләре
Язмыш уртак, куанычлар уртак,
Бер ояда тормыш корганда,
Хәтер калдырулар нигә кирәк,
Матур көннәр туып торганда?

Кушымта:
Араларны суытмасын
Бәгырьсезлек салкыны!
Авыр сүздән сүрелмәсен
Йөрәкләрнең ялкыны!

Бер омтылыш белән яшәгәндә
Аңлашмаслык эшләр бармыни;
Җылы сүзләр белән сабырлыкка
Күңелләрдә урын тармыни?

Кушымта:

Араларны суытмасын
Шәфкатьсезлек салкыны!
Авыр сүздән сүрелмәсен
Йөрәкләрнең ялкыны!

Бер-береңне аңлап, хөрмәт итеп
Яшәүләргә гөрләп ни җитә!
Дәрт чаткысы сүнә, күңел сула,
Рәнҗетүдән йөрәк кимсенсә.

Кушымта:
Араларны суытмасын
Җәберсетү салкыны!
Авыр сүздән сүрелмәсен
Йөрәкләрнең ялкыны!

### Шомырт чӘчӘклӘре хӘтерле

*Шамил Маннапов* сүзләре
Онытырга сине теләсәм дә,
Оныталмыйм нигә, әйтимме? —
Шомырт чәчәкләре төшерә искә,
Шомырт чәчәкләре хәтерле.

Шомырт чәчкәседәй ак күлмәгең,
Шомырт төсле кара күзләрең.
Шомырт кәүсәседәй бөгелә-сыгыла
Су буеннан кайтып килгәнең.

Сөйли миңа шомырт чәчәкләре,
Шомырт чәчәкләре хәтерле.
Шомырт чәчәкләре төшерә искә
Шомырт чәчәгедәй яшьлекне.

Шомырт чәчәгедәй, башым иеп,
Шомырт янына киләм һәр көнне.
Шомырт чәчәкләре төшерә искә,
Шомырт чәчәкләре хәтерле.

Шомырт чәчәкләре хәтерле...

### Җыр сораган чагы кҮҢелемнеҢ!

*Гарифҗан Мөхәммәтшин* сүзләре
Чыгам кабат туган кырларыма,
Офыкларым зәңгәр-күгелҗем,
Җырлап үтәм арыш басуларын,
Җыр сораган чагы күңелемнең!
Җырлыйк әйдә,
Җырлыйк әйдә,
Җыр сораган чагы күңелемнең!

Сөенечем сыймый күкрәгемә,
Моңнар ага ташып күңелемнән,

Бәхет җырын җырлый тугайларым,
Тургай кушыла биек күгеннән.
Җырлыйк әйдә,
Җырлыйк әйдә,
Җыр сораган чагы күңелемнең!

Гомерем буе, сөеп туган җирне,
Күпме назлы җырлар җырладым,
Башка җырлар кирәк түгел миңа,
Җырлап торган чакта кырларым.
Җырлыйк әйдә,
Җырлыйк әйдә,
Җыр сораган чагы күңелемнең!

## зӘйтҮнгӨл Җыры

*(«Зәйтүнгөл» спектакленнән)*

*Нәҗип Әсәнбаев* сүзләре

Таң нурларын күз яшенә манчып
Озатып калганнарым еракта.
Көтә белсәң, җиңеп кайтырмын, дип
Әйтеп киткән сүзең колакта. 2 тапкыр

Бер үк сукмаклардан йөргәнбез,
Бер үк чишмәнең суын эчкәнбез.
Авыл очындагы куш каеннар,
Бер кояшка карап үскәнбез. 2 тапкыр

Ничек яшәр идек бу дөньяда,
Әгәр икәү бергә булмасак.
Бәхет кошы читләп үтәр иде,
Бер-беребез өчен тумасак. 2 тапкыр

Бәхет тә бит җырчы кошка охшаш,
Аның да бар ике канаты.
Бер канаты аның — чын мәхәббәт,
Икенчесе — сайрар бакчасы. 2 тапкыр

## иҢ якын дус — беренче дус

Нәби Дәүли сүзләре

Бакчаларга чыгам яз булганда,
Искән чакта җылы таң җиле.
Тирәкләрдә кошлар сайраганда
Очратырмын кебек мин сине.

Йолдызларны күрсәм кич булганда,
Җыр ишетсәм Идел ярында,
Син киләсең кебек шул чагында
Җырлый-җырлый минем яныма.

Иң якын дус — беренче дус,

Югалтсаң — ул табылмас.
Беренче дустың шикелле
Яңадан ярың булмас.

Сукмаклардан узам көз булганда,
Сары яфрак җиргә сибелгән.
Тәрәзәгә барып карар идем,
Тәрәзәңдә инде ут сүнгән.

Йөрәгемдә бары син булганга,
Искә төшә язгы көн генә.
Кавышмадык нигә без ул язда,
Гаепле тик син дә мин генә.

Иң якын дус — беренче дус,
Югалтсаң — ул табылмас.
Беренче дустың шикелле
Яңадан ярың булмас.

## Эх, Арча читеклӘре

*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре
Сөйгәнемә читек эзләп,
Урап кайттым Арчаны.
Рәхим итеп,
Мә, ал читек —
Аллы-гөлле парчалы!

Кушымта:
Эх, Арча читекләре!
Чигүле дә,
Каюлы да,
Үкчәле дә үзләре.
Янып торган бизәкләре
Камаштыра күзләрне!

Белми йөргәнмен читекнең
Нәфис кием икәнен.
Кигәч аны,
Артты тагы
Матурлыгы иркәмнең.

Кушымта.

Читек тегүче осталар
Алтын куллы, сөйкемле.
Хискә кайнар,
Эштә алар —
Язгы гөлләр шикелле!

Кушымта.

Эх, Арча читекләре!..

## АЙЛЫ КИЧ

*(Вальс)*

*Әхмәт Ерикәй* сүзләре
Айлы кичне яратам мин,
Кошлар сайрап торганда,
Ай тулганда, җил тынганда,
Син янымда булганда.

Кушымта:
Бормалап ага елга,
Җир йөзе күмелә нурга.
Җырлыйсым килә шунда.

Айлы кичне җанга рәхәт
Табигать кочагында.
Ике йөрәк бер йөрәктәй
Бергә типкән чагында.

Кушымта.

## Ник ӘйлӘнеп карамадыҢ?

*Хәмит Төхвәтуллин* сүзләре
Ник әйләнеп карамадың,
Соңгы тапкыр күрешеп киткәндә,
Нигә, бәгърем, син дәшмәдең,
Соңгы тапкыр кулың үпкәндә?

Кушымта:
Кайгыларым онытылыр инде,
Бер генә миңа карасаң.
Күңел күзе белән карар идең,
Әгәр дус дип мине санасаң.

Син китсәң дә, синең белән
Минем мескен арган йөрәгем.
Төшләремдә һаман сине күрәм,
Өнемдә дә күрү — теләгем.
Кушымта.

## кӨзге Җыр

*(Романс)*

*Рамазан Байтимеров* сүзләре
Тагын язлар үтте, көзләр җитте,
Кыр-урманнар сары киенә.
Еракларга очкан аккошлар да
Җыр сузалар сагыш көенә.

Гомеремнең җитте сары көзе,
Күп инешләр акты, күп сулар.
Яфракларын койган агачлар да

Минем кебек бигрәк моңсулар.

Сагышланма әле, күңелкәем,
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Нинди генә чәчәк шиңми калган,
Нинди генә гөлләр кипмәгән.

Җиргә тагын яңа язлар килер,
Гөлчәчәкләр үсәр кырларда.
Күңел нурым калыр, урын алыр
Йөрәгемнән чыккан җырларда.

## ҖиҢҮ кӨне ҖиҢел бирелмӘде

*Мансур Шиһапов* сүзләре
Яшь каеннар яфрак ярган таңда
Яшь каендай зифа егетләр,
Ил бурычын иңнәренә асып,
Утка төренеп яуга керделәр.

Кушымта:
Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк җылый Муса, Алиш өчен,
Егермеләп миллион җан өчен!

Тарих шаһит — үлмәс Карбышевлар
Әверелә бозга — ил сатмый.
Татар улы — батыр Газинурлар —
Күкрәкләре белән ут каплый.

Кушымта.

Яңгыра, җыр, тыйнак илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып,
Батырлыгы булып халкымның!

Кушымта.

## Бик кҮрӘсем килӘ

*Әхмәт Ерикәй* сүзләре
Торсам иртән, уйларымда йөртәм,
Ятсам, төшләремә керәсең.
Бик сагындым, иркәм, нишлим икән,
Бик күрәсем килә, күрәсем.

Әллә ят кешеләр, әллә үзең
Кавышу өметләрен җимрәсең.
Көтә-көтә талды ике күзем,
Бик күрәсем килә, күрәсем.

Алмаштырмый хатка язган сүзләр,
Алмаштырмый сине бу рәсем.
Белмим инде, йөрәк ничек түзәр,
Бик күрәсем килә, күрәсем...

## тӨнбоек чӘчӘклӘре

*Рәфкать Шакиров* сүзләре
Су буйларына төштем мин
Төнбоеклар өзәргә.
Яшьлек дустым ерак калды,
Туры килә түзәргә.

Төнбоеклар моңаялар,
Салкын җилләр искәндә.
Мин дә шулай моңаямын,
Син исемә төшкәндә.

Иртән чыклар төшеп күмә
Төнбоек чәчәкләрен.
Аерылган минутларның
Белмәдем сәбәпләрен.

## САГЫНАМ УРАЛ БУЙКАЕН

*Әшрәф Талипов* сүзләре
Сагынамын Урал буен,
Әллә шунда үскәнгә.
Моңланып җырлап җибәрәм,
Исләремә төшкәндә.

Урал буйкаена чыксам,
Күзем карап туялмый.
Ямьле Урал буйкайлары
Күз алдымнан югалмый.

Кайда гына мин булсам да,
Сагынам Урал буйкаен,
Сагынам Урал буйкайларын,
Шунда татлы уйларым.

Ямьле Урал буйларында
Аккош бала уйната.
Урал буе исемә төшсә,
Уйлата да җырлата.

Җырлата да елата...

## ИсӘ ҖиллӘр

*Нурмөхәммәт Хисамов* сүзләре
Исә җилләр сискәндереп,
Озак хәбәр булмаса,

Вәгъдә нихәл икән, диеп,
Мең төрле шик, шом баса.

Биргән антлар, язган хатлар
Калдымы җил иркенә?
Күз аттымы әллә ятлар
Буйларыңа, күркенә?

Исә җилләр өзеп-өзеп,
Күгем сырып болытка.
Пышылдыйлар үзәк өзеп:
«Оныткан, ди, оныткан».

### Җамалый такмаклары

*(«Кияүләр» спектакленнән)*

*Хәй Вахит* сүзләре
Карагыз бу сөенечне,
Бу шатлыкны карагыз.
Кызыбыз кияүгә чыккан,
Бүген туйга барабыз.

Үзенә тиң ярын тапкан
Күрер көннәр бар икән.
Туйларында куанышып
Йөрер көннәр бар икән.

Шатлыкларга, бәхетләргә
Күмелсен гомерләре.
Бер-берсенә гомерлеккә
Беркелсен күңелләре.

Менә нинди куаныч.
Без картларга юаныч.

Җырлый-җырлый, бии-бии
Туй итәбез иртәгә.
Икесенә бәхет теләп,
Бүләк илтик яшьләргә.

Бавырсаклар, тозлы казлар,
Төрле-төрле хөрмәтләр —
Бары да булсын, өстәл тулсын
Кызым балам туенда.

Шатлыкларга, бәхетләргә
Күмелсен гомерләре.
Бер-берсенә гомерлеккә
Беркелсен күңелләре.

Менә нинди куаныч.

Без картларга юаныч.

Сине генӘ сагынам

*Әхмәт Рәшит* сүзләре
Йөрәгемә сагыш уты өстәп,
Алмагачлар ак шәл ябынган.
Ә мин сине, солдат сөйгәнемне,
Бары сине генә сагынам.

Матур сүзләр сөйләп, бар егетләр
Каш сикертеп уза янымнан.
Башкаларга күзем төшәр димә,
Бары сине генә сагынам.

Тәүге үбүләрем вәгъдә сиңа,
Гыйшкым уты синнән кабынган.
Көннәр буе, айлар, еллар буе
Бары сине генә сагынам.

Сөйгәнемә җырым сәлам илтсен
Туып үскән Идел ягыннан.
Онытма син, бәгърем, онытма син,
Бары сине генә сагынам.

Туй итӘ Казан

*Сибгат Хәким* сүзләре
Батыр һәйкәле алдына,
Өзеп алып хисләрдән,
Салалар туй чәчәкләре
Яңа өйләнешкәннәр.

Киләчәк бөек эшләргә
Үзен багышлый яшьлек.
Уйлана ерак чорларга
Узып барышлый яшьлек.

Гөр килеп туй итә яшьлек,
Үзе башкода Казан,
Ленталар белән бизәлеп,
Кая ашкына Казан?

Киләчәк якты елларның
Каршына чаба Казан.

АҢла, дустым

*Әхсән Баян* сүзләре
Шауласа кичен агачлар
Йомшак җил кагылудан,
Аңла, дустым, мин җырлармын,
Җырлармын, җырлармын сагынудан.

Кичке җилләр йомшак кына
Сыйпаса битләреңнән,
Аңла, дустым, мин аерылмам
Саф сөю, саф сөю хисләреннән.

Тулган ай чыкса һавага,
Агылса саргылт нурлар,
Аңла, дустым, таңга кадәр
Күңелем, күңелем сине уйлар.

Елмайса кырлар, авыллар
Таңгы нур сибелүдән,
Аңла, дустым, без гел бергә
Гомергә, гомергә синең белән.

## ДиҢгез тӨне

*(Романс)*

*Кави Нәҗми* сүзләре
Тымызык якты төште ак комнарга,
Ай нурлары кабындылар дулкыннарга;
Кил, акыллым, килче, җаным, диңгезгә кил
Дулкын белән айның дуэтын тыңларга.

Дулкыннарның өсләреннән тая-тая,
Ай шәүләсе сукмак сала миңа таба;
Шул чагында син исемә төшәсең дә,
Айны онытып, сиңа кайтам чаба-чаба.

## ТУГАЙЛАРЫМ

*Илсөяр Ганиева* сүзләре
Тугайларым, ахры, мине гашыйк итте,
Күңелем калды шунда бәйләнеп.
Агыйделкәй, кайтырмын ла сиңа,
Киек казлар кебек әйләнеп.

Кушымта:
Юксынма, вакытлыча гына китәмен,
Җырларыма салып синең гүзәллегең
Якын дусларыма илтәмен.

Нигә сине шулай өзелеп яратуның
Үзем генә беләм серләрен.
Йөрәгемә сүнмәс хисләр салдың,
Иң кадерле туган җирләрем.

Кушымта.

## САУМЫ, АВЫЛЫМ

*Рамазан Байтимеров* сүзләре
Сагынулар — сары алтын,

Моң-сагыш тулы ялкын.
Бар җирдән дә күңелемә
Туган авылым якын.

Кушымта:

Саумы, авылым!
Сагынып кайттым
Бөреле талларыңны,
Кәккүкле урманнарыңны,
Былбыллы таңнарыңны.

Якты яшьлегем язлары
Калган сиңа бәйләнеп.
Кайларда гына йөрсәм дә,
Сагынып кайттым әйләнеп.

Кушымта.

Язгы яшел үләннәргә
Ятып ауныйсым килде.
Кырларыңда тирләп-пешеп
Уңыш яулыйсым килде.
Кушымта.

### Язгы гӨлем

*Әхмәт Рәшит* сүзләре
Томанлы көн сыман күз карашың,
Үпкәләвең юкка түгелме?
Йә, елмайчы, бәгърем, язгы гөлем,
Әрнүләрен басып күңелнең.

Пар күгәрчен кебек гөрләшкәндә,
Мәхәббәткә нигә күләгә?
Керсез сөюемә, язгы гөлем,
Авыр сүзләр белән түләмә.

Илтифатсыз булсам кайчакларда,
Кичер мине — юк-бар уйлама.
Калдыр мәхәббәтең, язгы гөлем,
Яшьлегеңнән алтын туйга да.

### Син аҢларсыҢ минем йӨрӘгемне

*Булат Сөләйманов* сүзләре
Таң нурлары уйный көнчыгышта,
Урман жырлый сихри моңнарын.
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Чиртеп кара күңлем кылларын.

Таштан ташка сикереп чишмә ага,
Серләрен ул сөйли камышка.
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Башкаемны салма сагышка.

Әйдә барыйк, иркәм, урманнарга,
Урап үтик чишмә буйларын.
Син аңларсың минем йөрәгемне,
Аңларсың ла сөю моңнарын.

САГЫШ

*Рамазан Байтимеров* сүзләре
Язмыш илтте яшьли еракларга,
Йөрәк ничек ярсып типмәсен?!
Читтә яшәп, читтә картаерга
Беркемгә дә насыйп итмәсен.

Тезелешеп кошлар кайткан чакта,
Карый идем күккә каерылып.
Кошларның да калмый бәхетлесе
Туып үскән җирдән аерылып.

Туган җирне кайтып бер күрсәм дә,
Мин үкенмәс идем, үлсәм дә.
Баш очына салып калдырырга
Туфраккаен йөрттем кесәмдә.

БЕЗ — КАЗАН КЫЗЛАРЫ

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Идел буенда тудык без,
Идел суын эчтек без.
Идел камышлары кебек
Зифа булып үстек без.

Безнең Казан — матур кала
Ямьле Идел буенда.
Егетләр безне күзлиләр
Язгы сабан туенда.

Мәскәүдән дә, Уфадан да
Яучылар килә безгә.
Кияү егетләре йөри
Әйләнә-тирәбездә.

Мәскәү-Уфа егетләре
Күп килеп йөрмәсеннәр.
Яңа бистә егетләре
Көнләшә күрмәсеннәр.

Үз илемдӘ

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Яз да сайрый, көз дә сайрый
Бер нәни кош бакчамда.
Шул кошны сагынып кайтам,
Кая гына барсам да.

Бакчам гади, үсми анда
Кипарислар, хөрмәләр,
Миңа таллар кипаристан
Матуррак күренәләр.

Исем китми читтә үскән
Әфлисунга, бананга.
Әче булса да, гашыйк мин
Миләш белән баланга.

Мин гашыйк илемдә үскән
Талларның барчасына,
Үз илемдә ямьле миңа
Бәрәңге бакчасы да.

Фирдания

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Маляр кыз Фирданияның
Күз иярми кулларына.
Ул буяган йортка керсәң,
Уйный якты нурлар гына.

Кушымта:
Фирдания, Фирдания!
Буяулары аллы-гөлле.
Аллы-гөлле чәчәк кебек,
Ул үзе дә бик күңелле!

Кояш кебек балкып тора
Ул буяган стеналар,
Кешеләрнең күңеленә
Шатлык нуры өсти алар.

Кушымта.

Карлыгач шикелле җитез,
Эшкә очып кына бара.
Кешеләрне шатландырып,
Ул үзенә шатлык таба.

Кушымта.

Син чыгасыҢ, ӘнкӘй, коега

*Сибгат Хәким* сүзләре
Кая барсам, кайда йөрсәм дә мин,
Күңелемә шулай тоела:
Пар кулыңа пар чиләгең асып,
Син чыгасың, әнкәй, коега.

Изге теләк теләп үстердең син,
Бассыннар, дип, тизрәк аякка,
Шул сүзләрең синең искә төшә,
Юнәлсәм дә хәзер кай якка.

Кое янында син ишетерсең
Миннән сиңа хәбәр килгәнен,
Син һәркемгә очрыйсыңдыр, әнкәй,
Мөлдерәмә килеш чиләгең...

Девятай

*Советлар Союзы Героена*

*Мостафа Ногман* сүзләре
Дәһшәтле сугыш еллары,
Җимерелә авыл, кала,
Шул сугышта Девятаев
Дошман кулында кала.

Кушымта:
Девятай, Девятай,
Казан егете Девятай,
Дошманнарның оясыннан
Очып кайткан Девятай.

Ул оча дусларын алып
Фашистлар торган җирдән,
Туган иле ул батырга
Кайрылмас канат биргән.

Кушымта:
Девятай, Девятай,
Казан егете Девятай,
Дошманнарның оясыннан
Очып кайткан Девятай.

Тетрәмәгән, баш имәгән
Фашист тоткынлыгына,
Дошман самолетын алып
Кайта туган ягына.

Кушымта:
Девятай, Девятай,
Ил батыры Девятай,
Дошманнарның оясыннан
Очып кайткан Девятай.

Мин сагынам яз иртӘсен

*(Язгы уйлар, язгы моңнар)*

*Нәби Дәүли* сүзләре
Мин сагынам яз иртәсен,

Аккан чакта ташкын сулар.
Йөрәгемдә чаң кагалар
Язгы уйлар, язгы моңнар.

Йолдызларга сузылмадым —
Нигә йолдыз, җирем булгач.
Миңа җитә бер ярты ай
Һәм бер талда бер сандугач.

Мин шуңа да риза идем,
Ул көннәрне кем сагынмас?
Миңа бер җыр бүләк итеп
Очып китте ул сандугач.

Тагын күпме алда гомер,
Язмыш әле нәрсә язар?
Җирдә күбрәк торган саен
Азрак кала миңа язлар.

Азрак кала миңа язлар.

Татарча «Ча-ча»

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Җырлыйк, дуслар, биик, дусларым,
Җырлап биюләр күңелне ача.
Арчалар җырлый, арчалар бии,
Бик матур бию — «Ча-ча-ча-ча-ча»!

Кушымта:
Кубалар бии, болгарлар бии,
Руслар да бии «Ча-ча-ча-ча-ча»!
«Бу нинди бию?» — дип сорасагыз,
Ә мин биимен татарча «Ча-ча-ча»!

Эшләр уң булса, уңыш мул булса,
Биисе килә, җырлыйсы килә!..
Бөтен җир йөзен, тормышның үзен
Бизисе килә, нурлыйсы килә!..

Кушымта.

# Эчтәлек

Төзүчедән. *Л.Любовский* .............
Ак калфак көе. *М.Фәйзи* сүзләре .........
Җил икән... *Х.Туфан* сүзләре ...........
Ник соңладың? *И.Ганиева* сүзләре ........
Кичке нурлар. *М.Ногман* сүзләре ........
Горурлыгым. *Н.Хисамов* сүзләре .........
Серле кара күзләр. *М.Шәехова* сүзләре .....
Кайларда сез? *Н.Хәсәнов* сүзләре .........
Авылым — алтын бишегем. *Х.Бәдретдинов* сүзләре .......................
Гомер. *Г.Рәхим* сүзләре ...............

Картаймагыз әле, ветераннар! *Г.Рәхим* сүзләре
Чирмешән. *М.Ногман* сүзләре ..........
Сине озатканда. *Н.Дәүли* сүзләре ........
Беренче тапкыр күрүем. *Х.Туфан* сүзләре ...
Ешрак яз, әнием, хатларыңны. *Р.Фазлыев* сүзләре ......................
Яшь күңел. *Г.Зәйнашева* сүзләре .........
Казан утлары. *Ә.Ерикәй* сүзләре .........
Әйт, дускаем, әйт. *Р.Янбулатова* сүзләре .....
Соңгы минутлар. *М.Шәехова* сүзләре ......
Әнисәм. *Г.Палютин* сүзләре ...........
Күзләрең, күзләрең... *К.Тәхау* сүзләре .....
Белегез шуны. *И.Фазлуллин* сүзләре .......
Без яшәгән өйнең бусагасы... *Р.Әхмәтҗан* сүзләре ......................
Кашларың карасына ла... *Р.Фәйзуллин* сүзләре
Кояш чыккан, баткан якта. *Р.Байтимеров* сүзләре ........................
Якты өмет. *Р.Юныс* сүзләре ............
Сөмбел. *Ә.Ерикәй* сүзләре .............
Якты елга моңнары. *Р.Ишморат* сүзләре ....
Безнең җыр. *Р.Гаташ* сүзләре ..........
Шәһәр төшләре. *И.Юзеев* сүзләре ........
Күңелләрдә урын тармыни? *З.Фәйзи* сүзләре .
Шомырт чәчәкләре хәтерле. *Ш.Маннапов* сүзләре ........................
Җыр сораган чагы күңелемнең! *Г.Мөхәммәтшин* сүзләре ....................
Зәйтүнгөл җыры. *Н.Әсәнбаев* сүзләре .....
Иң якын дус — беренче дус. *Н.Дәүли* сүзләре
Эх, Арча читекләре. *М.Хөсәен* сүзләре ......
Айлы кич. *Ә.Ерикәй* сүзләре ............
Ник әйләнеп карамадың? *Х.Төхвәтуллин* сүзләре ........................
Көзге җыр. *Р.Байтимеров* сүзләре ........
Җиңү көне җиңел бирелмәде. *М.Шиһапов* сүзләре ........................
Бик күрәсем килә. *Ә.Ерикәй* сүзләре .......
Төнбоек чәчәкләре. *Р.Шакиров* сүзләре .....
Сагынам Урал буйкаен. *Ә.Талипов* сүзләре ...
Исә җилләр. *Н.Хисамов* сүзләре .........
Җамалый такмаклары. *Х.Вахит* сүзләре ....
Сине генә сагынам. *Ә.Рәшит* сүзләре ......
Туй итә Казан. *С.Хәким* сүзләре ..........
Аңла, дустым. *Ә.Баян* сүзләре ...........
Диңгез төне. *К.Нәҗми* сүзләре ..........
Тугайларым. *И.Ганиева* сүзләре ..........
Саумы, авылым. *Р.Байтимеров* сүзләре .....
Язгы гөлем. *Ә.Рәшит* сүзләре ...........
Син аңларсың минем йөрәгемне. *Б.Сөләйманов* сүзләре ....................
Сагыш. *Р.Байтимеров* сүзләре ..........
Без — Казан кызлары. *Г.Зәйнашева* сүзләре ..
Үз илемдә. *Г.Зәйнашева* сүзләре ..........
Фирдания. *Г.Зәйнашева* сүзләре .........
Син чыгасың, әнкәй, коега. *С.Хәким* сүзләре ..
Девятай. *М.Ногман* сүзләре ............
Мин сагынам яз иртәсен. *Н.Дәүли* сүзләре ...
Татарча «Ча-ча». *Г.Зәйнашева* сүзләре .....